Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР №V-1**

Балык Бистәсе штп. 2020 елның 03 декабре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2012 елның 4 октябрендәге “Эшчәнлекнең аерым төрләре өчен алдан йөкләнгән керемгә бердәм салым рәвешендә салым салу системасын гамәлгә кертү турында” гы XX-3 номерлы карарының үз көчен югалтуын тану хакында

“Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә һәм “Банклар һәм банк эшчәнлеге турында” Федераль законның 26 маддәсенә үзгәрешләр кертү хакында” 2012 елның 29 июнендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законның 5 маддәсенең 8 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2012 елның 4 октябрендәге “Эшчәнлекнең аерым төрләре өчен алдан йөкләнгән керемгә бердәм салым рәвешендә салым салу системасын гамәлгә кертү турында” XX-3 номерлы карарын 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көчен югалткан дип танырга.
2. Карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.
3. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырып игълан итәргә.
4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының бюджет, финанслар, икътисад, җирле салымнар һәм эшкуарлык буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы И.Р. Таҗетдинов